ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы составына керүче «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (IX өлеш); 2014, № 12 (VIII өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1нче кушымта

# «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- 11 - тоташу ноктасының тәртип саны
- <u>10</u> - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

1 (60) – 16 (61) - Мамадыш муниципаль районы
16 (61) – 20 (62) - Алабуга муниципаль районы
20 (62) – 26 (87) - Тукай муниципаль районы
26 (87) – 39 (84) - Зәй муниципаль районы
39 (84) – 41 (83) - Әлмәт муниципаль районы
41 (83) – 10 (82) - Яңа Чишмә муниципаль районы
10 (82) – 1 (60) - Чистай муниципаль районы

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы номеры | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Түбән Кама шәһәре |
| 2 | Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Афанас авыл җирлеге |
| 4 | Ялантау авыл җирлеге |
| 5 | Каенлы авыл җирлеге |
| 6 | Кармалы авыл җирлеге |
| 7 | Кызыл Чапчак авыл җирлеге |
| 8 | Кызыл Чишмә авыл җирлеге |
| 9 | Майская Горка авыл җирлеге |
| 10 | Макаровка авыл җирлеге |
| 11 | Түбән Уратма авыл җирлеге |
| 12 | Прости авыл җирлеге |
| 13 | Сосновка авыл җирлеге |
| 14 | Иске Чишмә авыл җирлеге |
| 15 | Сухарево авыл җирлеге |
| 16 | Ширәмәт авыл җирлеге |
| 17 | Шәңгәлче авыл җирлеге |

»;

2) 3 нче кушымтада:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Прости авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,9 км Комлык утравының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 600 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап бара, шуннан соң, инешләрне һәм агач-куак массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, инешләрне һәм яр буендагы агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, инешләрне кисеп үтеп, 150 м сазлык буйлап, 750 м Түбән Кама – Соболеково автомобиль юлы буйлап уза, аннары, инешләрне һәм яр буендагы агач-куак массивларын берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң инеш агымы буйлап 50 м өскә таба уза, аннары, инешләрне берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, гараж кооперативының төньяк, көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, чокырларны, профильле автомобиль юлына һәм Түбән Кама – Прости автомобиль юлына бүлеп

бирелгән полосаларны, инешләрне, агач-куак һәм урман массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 6,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бикләп участок урманчылыгындагы 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, алга таба әлеге урманчылыкның урман ызаны буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, 450 м көньякка таба, 400 м төньяк-көнбатышка таба, аннары, сынык сызык ясап, әлеге урман массивының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш ягыннан 1,9 км көньякка таба, 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң, сынык сызык ясап, 80 м көньяк-көнбатышка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бикләп участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталының урман массивы чигенә кадәр, аннары 350 м әлеге урман массивы чиге буйлап көнбатышка таба бара, алга таба, сынык сызык ясап, 79 нчы урман кварталы чигенә кадәр 170 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары 140 м әлеге урман массивы чиге буйлап, шуннан соң, сынык сызык ясап, 260 м көньяк-көнбатышка таба 78 нче урман кварталының урман массивы чиге буйлап, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба әлеге урман массивы буйлап, аннары 60 м көньяк-көнбатышка таба урман ызаны буйлап, аннары 110 м әлеге урман массивының көньяк-көнбатышына, шуннан соң, юлны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 210 м, аннары, сынык сызык ясап, 270 м төньяк-көнбатышка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бикләп участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталы урман массивы чиге буйлап, шуннан соң, сынык сызык ясап, 480 м көньяк-көнбатышка таба 89 нчы урман кварталының урман массивы чиге буйлап «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 9,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасыннан алып «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылы чигеннән 8,9 км көньякта урнашкан 21а тоташу ноктасына кадәр, шулай ук Прости авылы чигеннән 8,8 км көньякта «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан 21б тоташу ноктасыннан алып «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Шәңгәлче авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ключ Труда поселогыннан 3,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Прости авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә 21а тоташу ноктасыннан, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бикләп участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталы урман массивын кисеп,

төньяк-көнбатышка таба 150 м, алга таба 300 м автомобиль юлы буйлап төньякка таба, аннары 240 м көнбатышка таба юл буйлап, аннары 400 м төньякка таба авыл юлы буйлап, 550 м көнбатышка таба «Көньяк» автомобиль юлының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 30 м төньякка таба урман ызаны чиге буйлап, аннары 190 м төньяк-көнбатышка таба юл чиге буйлап, 950 м «Көньяк» автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап, аннары 1,8 км көнбатышка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 73, 74, 75 нче урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 350 м, автомобиль юлын кисеп үтеп, 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекләренең көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 700 м төньякка автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 380 м көнчыгышка таба сәнәгать зонасының төньяк чиге буйлап, аннары 225 м көнчыгышка таба 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, алга таба 300 м әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба бара, аннары 195 м көнчыгышка таба әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары 400 м, сынык сызык ясап, сәнәгать мәйданының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба уза, шуннан соң 80 м көнчыгышка таба сәнәгать мәйданының төньяк чиге буйлап уза, 140 м көньякка таба сәнәгать мәйданчыгының көнчыгыш чиге буйлап, 160 м көнчыгышка таба әлеге сәнәгать мәйданчыгының көньяк чиге буйлап, 260 м төньякка таба, сынык сызык ясап, сәнәгать мәйданының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба автомобиль юлы чиге буйлап 285 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 850 м көньякка таба автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 160 м көньяк-көнчыгышка таба тимер юл буйлап уза, аннан соң, тимер юлны кисеп, 250 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап үтә, 60 м көньякка таба, тимер юлны кисеп, 135 м көнчыгышка таба, алга таба 1,5 км көнчыгышка таба, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталын кисеп үтеп, аннары, 76 нчы урман кварталын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 240 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 200 м төньякка таба 76 нчы урман кварталы буйлап, аннары 180 м көнчыгышка таба таш түшәлмәгән юл буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 150 м көньякка таба «Көньяк» автомобиль юлының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 77 нче урман кварталын кисеп үтеп, 350 м «Көньяк» автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба, алга таба 260 м көньякка таба 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекләренең көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 260 м көнчыгышка таба әлеге урман кварталы чиге буйлап, аннары, 78 нче урман кварталын, буаны кисеп үтеп, 600 м көнчыгышка таба, алга таба, 78 нче урман кварталы кишәрлекләрен кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м автомобиль юлының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, 78 нче, 89 нчы урман кварталлары кишәрлекләрен кисеп үтеп, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 660 м көньяк-көнчыгышка таба 89 нчы урман кварталы урман массивы чиге буйлап 21б тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 14 нче кушымтада:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Прости авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (62 нче) тоташу ноктасыннан Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Прости авыл җирлеге, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 9,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Прости авыл җирлеге чиге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,9 км Комлык утравының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 600 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап бара, шуннан соң, инешләрне һәм агач-куак массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, инешләрне һәм урман-куак полосаларын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 150 м сазлык буйлап, 750 м Түбән Кама – Соболеково автомобиль юлы буйлап уза, аннары, инешләрне һәм яр буендагы агач-куак массивларын берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң инеш агымы буенча 50 м өскә таба уза, аннары, инешләрне берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, гараж кооперативының төньяк, көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,4 км көньяк-көнбатышка таба уза, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, чокырларны, профильле автомобиль юлына һәм Түбән Кама – Прости автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны, инешләрне, агач-куак һәм урман массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 6,9 км бара, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, алга таба әлеге урманчылыкның урман ызаны буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, 450 м көньякка таба, 400 м төньяк-көнбатышка таба, аннары, сынык сызык ясап, урман ызанының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш ягыннан 1,9 км көньякка таба, 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң, сынык сызык ясап, 80 м көньяк-көнбатышка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталы массивы чигенә кадәр, аннары 350 м көнбатышка таба әлеге урман массивы чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 79 нчы урман кварталы урман массивы чигенә кадәр 170 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары 140 м әлеге урман массивы чиге буйлап, шуннан соң, сынык сызык ясап, 260 м көньяк-көнбатышка таба 78 нче урман кварталы урман массивы чиге буйлап, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба әлеге урман массивы буйлап, аннары 60 м көньяк-көнбатышка таба урман ызаны буйлап, аннары 110 м әлеге урман массивының көньяк-көнбатышына, шуннан соң, юлны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 210 м, аннары, сынык сызык ясап, 270 м төньяк-көнбатышка таба «Түбән Кама

урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бикләп участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының урман массивы чиге буйлап, шуннан соң, сынык сызык ясап, 480 м көньяк-көнбатышка таба 89 нчы урман кварталының урман массивы чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Прости авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Прости авыл җирлеге, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 8,9 км көньякта урнашкан 21а тоташу ноктасыннан Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Прости авыл җирлеге, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 8,8 км көньякта урнашкан 21б тоташу ноктасына кадәр уза.

Прости авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 21а тоташу ноктасыннан, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 88 нче урман массивын кисеп, төньяк-көнбатышка таба 150 м, алга таба 300 м автомобиль юлы буйлап төньякка таба, аннары 240 м көнбатышка таба юл буйлап, аннары 400 м төньякка таба авыл юлы буйлап, 550 м көнбатышка таба «Көньяк» автомобиль юлының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 30 м төньякка таба урман ызаны чиге буйлап, аннары 190 м төньяк-көнбатышка таба юл чиге буйлап, 950 м «Көньяк» автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап, аннары 1,8 км көнбатышка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 73, 74, 75 нче урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 350 м, автомобиль юлын кисеп үтеп, 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекләренең көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 700 м төньякка таба автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап бара, алга таба 380 м көнчыгышка таба сәнәгать зонасының төньяк чиге буйлап, аннары 225 м көнчыгышка таба 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, алга таба 300 м әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба бара, аннары 195 м көнчыгышка таба әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары 400 м, сынык сызык ясап, сәнәгать мәйданының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба уза, шуннан соң 80 м көнчыгышка таба сәнәгать мәйданының төньяк чиге буйлап уза, 140 м көньякка таба сәнәгать мәйданының көнчыгыш чиге буйлап, 160 м көнчыгышка таба әлеге сәнәгать мәйданының көньяк чиге буйлап, 260 м төньякка таба, сынык сызык ясап, сәнәгать мәйданының көнбатыш һәм төньяк чиге буйлап уза, аннары көнчыгышка таба автомобиль юлы чиге буйлап 285 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 850 м көньякка таба автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 160 м көньяк-көнчыгышка таба тимер юл буйлап уза, шуннан соң, тимер юлны кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап үтә, 60 м көньякка таба, тимер юлны кисеп үтеп, 135 м көнчыгышка таба, алга таба 1,5 км көнчыгышка таба, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 240 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 200 м төньякка таба 76 нчы урман кварталы буйлап, аннары 180 м көнчыгышка таба таш түшәлмәгән юл буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 150 м көньякка таба «Көньяк» автомобиль юлының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 77 нче урман кварталын кисеп үтеп, 350 м «Көньяк» автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба, алга таба 260 м көньякка таба 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 260 м көнчыгышка таба әлеге урман кварталы чиге буйлап, аннары, 78 нче урман кварталы кишәрлекләрен кисеп үтеп, 600 м көнчыгышка таба, алга таба 450 м, сынык сызык ясап, 78 нче урман кварталы кишәрлекләрен кисеп үтеп, автомобиль юлының көнчыгыш чиге буйлап, аннары, 78 нче, 89 нчы урман кварталлары кишәрлекләрен кисеп үтеп, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң 660 м көньяк-көнчыгышка таба 89 нчы урман кварталы урман массивы чиге буйлап 21б тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 50-ТРЗ

«Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган
**карта-схемасы**




- -Түбән Кама муниципаль районы чиге
- -авыл җирлеге чикләре
- -җирлекнең административ үзәге
- -Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге территориясе составына керүче Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе